**СОВЕТ ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, д.Чернышевка, ул. Клубная, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб ур., 1

тел./факс 8(84365) 73-5-05, e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**13 ноября 2023 г.** **№ 78**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында»2015 елның 15 октябрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Советы:

1. Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.10.2015 ел, № 14 карарына кертелергә (Советның 26.04.2018 ел, № 133, 14.09.2018 ел, № 152, 25.12.2018 ел, № 169, 30.11.2022 ел, № 60 карары редакциясендә), 13.09.2023 no 72) түбәндәге үзгәрешләр:

3 нче пунктның 3.2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

"3.2 Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге территориясендә мөлкәткә ия булган Россия Федерациясе физик затларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы: О.А. Маланин